| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11,10.2019 Алексеевск ш. т. б. № 467

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 декабрендәге 482 номерлы "Инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турындагы" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Алексеевск муниципаль районы прокуратурасы таләбенә туры китереп, ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатыннан, норматив хокукый актны үзгәртү турында 26.09.2009 елдагы 02-01-16/2019 номерлы Алексеевск муниципаль районы прокуратурасы таләбе нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 28 декабрендәге 482 номерлы карарына реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә (№10 Кушымта):

2.4. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып,Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне җибәрү вакыты, килештерүче оешмаларда муниципаль хезмәт күрсәтү турында теркәлгәннән соң, 59 календарь көн .<br>Документларны тапшырудан,карауга кадәр 1 календарь көн. | № 38-ФЗ Федераль законның 19 нчы статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | Карау срогыннан алып нәтиҗә бирүгә кадәр 58 календарь көн. | |

2. 9 пунктының 4 нче пунктчасын яңа редакциядә бирергә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 4) җирлек яки шәһәр округы төзелешенең тышкы архитектур йөзен бозу, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яки аның территориясенең бер өлешендә урнаштыруга рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән реклама конструкцияләренең төрләре булган очраклар,<br>мондый реклама конструкцияләренә таләпләр Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән; | № 38-ФЗ Федераль законның 19 нчы ст. 15 өл. |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А. Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**